Балтач муниципаль районы муниципаль бюджет төп гомуми белем учреждениесе
«Шубан төп гомуми белем бирү мәктәбе»

**Районның әхлак укытучылары республика семинарында үткәрелгән**
**“Кичке уен “**
**(җыр – биюле фольклор )**

**Беренче категорияле башлангыч сыйныф укытучысы**
**Шарипова Лилия Ураловна**

декабрь , 2022

Кичке уен

җырлы – биюле фольклор

Максат:
укучыларны милли рухта тәрбияләү,үткәннәрне онытмаска ,ихтирам итәргә төйрәтү, уйлау ,фикерләү сәләтләрен үстерү,үз халкыңның милли бәйрәмнәрен һәм йолаларын белүнең әһәмиятенә төшендерү ;
Җиһазлау : сәхнә авыл күренешен чагылдырып бизәлә ,кошлар сайравы ,иртәнге авыл тормышын чагылдырган көй ишетелә ,алда авыл өйләре , капкалар күренә .

Ике малай чыга көй астында

*( Ильназ)* -Рияз , әйдә кызларны чакырабыз.

- *( Рияз )* – Әйдәле.Кызлар ,әйдәгез , кичке уенга . ( сызгыралар)
- Әйдә качтык .
- *Карале ,үзләре чакырдылар , кайда былыр алар ?*
- *Чынлап та , кайда алар ?*
- - *Кхк-кх*
- *(Күке булып кычкыралар.)*
- Карале ,качканнар.Тагын бер шаяртып кына карагыз .( Эткәләп , төрткәләп җибәрәләр)
- Колакларын борырга кирәк.
- Әй ,егетләр чакыра дисәм, малайлар шаярта икән.
- **- әйе шуул**
- Ярар , кызлар ,җыелдыкмы ?
- **Җыелдык.**
- Уйныйбызмы ?
- **Уйныйбыз.**
- Мин башлыйм. ( Ильназ алга чыга )
  Утырып тор әле ( кире урынына этеп чыгара)
- , башың яшь,үзем кеше җыям . Кызлар , башлап кайсыгызны алыйм ?
- Әйдә, санамыш әйтәбез:
  *Арыш – бодай игәбез,*
  *Аны болай бүләбез:*
  *Тигез,уңган, таза , нык*
  *Таза ныкка – биш капчык.*
  *Ялкау ,чытык, мактанчык,*
  *мактанчыкка буш капчык.*
  *Буш капчык ,уенга чык!*
  ( Атлап бии башлый , калган кызлар мине ал , мине ал дип торалар. мине мине мине ал, )
  ( Кызларны алып бетергәч )
- Малайларны уйнатабызмы ? ( башта бер малайны , аннары икенчесен алалар)
- Түгәрәккә бастык .( бер әйләнәләр дә парлаштык дип кычкыралар)
- **Парлаштык.**

- **Син кем?**
- - Әйтмим.
- **Әйтәсең, әйтәсең.Син кем?**
- Әй, җебегән мин.
- ( кызлар көлешәләр)
- Җебегәнгә ни җәза?
- **Мунча кертәбез**.( почмак ясап парлашып басалар, җебегән уртада тора)
-

**Ай тердә риттәрәм**

**Вай тер дә риттәрәм (2)**

Мич башыннан төшмәгән

Мич башыннан төшмәгән

Ачык авыз җебегән

Ялгыз калды пешмәгән

**Ай тердә риттәрәм**

**Вай тер дә риттәрәм(2)**

( Шул вакытта малай йодрык күрсәтеп тора )

Малай үзенә пар алып уртадан чыгып китә.Ялгыз калган бала алга чыгып баса.

Тегеләре киңәшләшкән шикелле бергә җыелып алалар. Алда калган кыз симәнке ашап тора

Урамыгызда балчык
бата күрмә атлап чык
Син дә бездән артык түгел
Бераз гына мактанчык
( Үзенә пар алып уртадан чыгып китә , малай алга чыга)

**Ай тердә риттәрәм**

**Вай тер дә риттәрәм (2)**

- Чалбар балагы нишләгән?
  Әллә кәҗә тешләгән.
  Сина дигән кызлар әле
  Мич башыннан төшмәгән.
  ( малай йодрык күрсәтеп , уртадан пар алып чыгып китә )
  ,алда озын кыз кала)

**Ай тердә риттәрәм**

**Вай тер дә риттәрәм (2)**

-Алмагачның ботагында сайрап утыра карга
Нормальныйлар арасында нишләп йөрисең колга?

**Ай тердә риттәрәм**

**Вай тер дә риттәрәм (2)**

( Үзенә пар алып чыгып китә, елак чыга)

- Талиянең дусты килгән
  Күкәй ашатыйк микән
  Кунакчага менгән чакта
  Әтәч тибеп төшергән

**Ай тердә риттәрәм**

**Вай тер дә риттәрәм (2)**

( Елый башлый)

- Әй бозылды , бөтен уенны бозды.
- Елак ,елак,ертык колак
  Йорт сала да упадет (читкә китеп баралар)
  Баян тавышы ишетелә, балалар шул якка борылалар.
- Кызлар ,яшьләр түбән очтан киләләр бугай .
- Без карша алабаз.( ике малай йөгереп каршы чыгып китәләр,кызлар җыелышып сөйләшеп торалар.) (Ике малай арба тартып килеп керәләр,арбада гармунчы,берничә пар такмак җырлап иярep йөриләр)
-

-Җитәкләшеп ,тезелешеп ,урам буйлап барабыз.(2 тапкыр)
( арттан кергән балалар уртада калалар)
Шушында тукталабыз да ,җырлап биеп алабыз.(2 тапкыр)

- **Чабата биюе**
- **Айзилә бн. Алисә**

Ике якта ике малай кубызда уйный,кызлар җырлап уртага җыелалар.
Их зилем зиләйлүк.
Сандугачым кил әле.
Кил әле дустым кил әле
Икәү әйләник әле.
( Уртада әйләнешеп , кара-каршы тезелеп басалар.)
Алдан кергән кызлар икесе читән кырыенда , икесе эскәмиядә утыралар җырлап)
(бишенче кыз кыскачка тимер белән сугып тавыш чыгарып тора)
Их, зилем-зиләйлүкне җырлап , бию хәрәкәтләре белән җырлыйлар.
Җитәкләшеп , тезелешеп ,өйгә кайтырга вакыт(2т)
сезгә бәхет шатлык теләп ,дуслар , саубуллашабыз.

Их, зилем-зиләйлүк
Сандугачым кил әле
Кил әле дустым кил әле
Икәү әйләник әле.
( артта торганнары да алга кушыла)
Шушы матур айлы кичтә
Бергә әйләник әле.( 45 тапкыр)
-Уйнап көлеп,җырлап ,биеп байый күңелләребез
Иртәгә дә дускайларым , кичке уенга килегез.
-Ә хәзер айрылышабыз.
Ике баянчы кала ,арбага баяннарын салып ,сөйләшә сөйләшә керәләр.

- Карале ,Язилә,үзләренә кирәк чакта арбаларга утыртып, ялынып , ялварып кичке уенга алып килделәр дә
  Эш беткәч , качтылар да киттеләр.
- Әйе , Миндияр , иртәгә арба түгел, ат җигеп килсәләр дә кичке уенга чыкмыйм.
- Их,ялындыра .
- Их, яшьләр.

Җитәкләшеп , тезелешеп ,урам буйлап барабыз
Шушында тукталабыз да җырлап- биеп алабыз
Их зилем- зиләле, сандугачым кил әле
Кил әле дустым ,кил әле
Бергә әйләник әле.

Менә сиңа уң кулым ,менә сиңа сул кулым

Җитәкләшеп , тезелешеп өйгә кайтып барабыз.(2 тапкыр)
Сезгә тыныч йокы теләп , дуслар , саубуллашабыз.
Сезгә бәхет-шатлык теләп ,дуслар, саубуллашабыз.
Их зилем- зиләле, сандугачым кил әле
Шушы матур айлы кичтә
Бергә әйләник әле.
Шушы матур моңлы кичтә
бергә әйләник әле.

Уйнап-көлеп,җырлап- биеп
Байый күңелләребез.
Иртәгә дә дускайларым ,кичке уенга килегез.

- Ә хәзер айрылышабыз !

Ике баянчы кала ,арбага баяннарын салып ,сөйләшә сөйләшә керәләр.

- Карале ,Язилә,үзләренә кирәк чакта арбаларга утыртып, ялынып , ялварып кичке уенга алып килделәр дә
  Эш беткәч , качтылар да киттеләр.
- Әйе , Миндияр , иртәгә арба түгел, ат җигеп килсәләр дә кичке уенга чыкмыйм.
- Их,ялындыра .
- Их, яшьләр.